КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 июль г.Казань № 617

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 19 май, 356 нчы; 2016 ел, 16 июнь, 408 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2018 ел, 14 март, 152 нче; 2018 ел, 17 декабрь, 1153 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның икенче абзацында «(кабул итүне)» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2002 ел, 18 июль, 426 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 22 июль, 617 нче
карары редакциясендә)

# Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләре

## I. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү

1.1. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә һәм аларны үтәү йөзеннән чыгарыла.

1.2. Республика башкарма хакимият органы тарафыннан чыгарыла торган хокукый актлар төрләре бу орган турындагы нигезләмә белән билгеләнә. Норматив хокукый актларны хатлар, күрсәтмәләр яки телеграммалар рәвешендә чыгарырга рөхсәт ителми.

Республика башкарма хакимият органнарының структур бүлекчәләре һәм территориаль органнары норматив хокукый актлар чыгарырга хокуксыз.

1.3. Норматив хокукый актлар берничә республика башкарма хакимият органнары белән бергәләп яки аларның берсе тарафыннан икенчесе белән килештереп чыгарылырга мөмкин.

Башка республика башкарма хакимият органнары белән бергәләп яки килештереп чыгарылган норматив хокукый актларга әлеге республика башкарма хакимият органнары белән бергәләп яки килештереп үзгәреш кертелә яки алар үз көчен югалткан дип таныла.

1.4. Норматив хокукый актлар проектларына:

хокукый экспертиза ясалырга тиеш;

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла торган коррупциягә каршы экспертиза, шул исәптән коррупциягә каршы бәйсез экспертиза ясалырга тиеш;

республика башкарма хакимият органы каршындагы иҗтимагый советта законнар белән каралган очракларда һәм тәртиптә җәмәгатьчелек фикер алышуы, иҗтимагый экспертиза һәм фикер алышу үткәрелергә тиеш;

әгәр дә законнар нигезендә килештерү таләп ителсә, шулай ук әгәр дә норматив хокукый актлар проектларында башка республика башкарма хакимият органнарына кагылышлы нигезләмәләр булса, кызыксынучы республика башкарма хакимият органнары белән килештерелергә тиеш.

1.5. Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары һәм дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча административ регламентлар проектларына, шулай ук элек чыгарылган административ регламентларга үзгәрешләр кертү, административ регламентларны үз көчен югалткан дип тану турындагы норматив хокукый актлар проектларына дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын һәм дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча административ регламентларны эшләүне методик яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле оешма тарафыннан үткәрелә торган экспертиза ясалырга тиеш.

1.6. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән очракларда, республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары проектларының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы тарафыннан үткәрелә торган җайга салу йогынтысы бәяләнергә тиеш.

1.7. Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан норматив хокукый актлар проектларын эшләү Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан расланган норматив хокукый актлар проектларын юридик-техник рәсмиләштерү буенча методик тәкъдимнамәләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

## II. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу

2.1. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

2.2. Дәүләт теркәвенә алынырга тиешле норматив хокукый акт, аңа республика башкарма хакимият органы җитәкчесенең имзасы куелгач һәм ул тиешле республика башкарма хакимияте органында теркәлгәч, өч эш көне эчендә электрон образ рәвешендә Татарстан Республикасы электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелә. Электрон образ, норматив хокукый актка кул куелып теркәүгә алынганнан соң, аның кәгазь чыганагын сканерлау юлы белән булдырыла.

2.3. Республика башкарма хакимият органының норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алуга җибәрү турындагы иярчен хатына (алга таба – иярчен хат), норматив хокукый акттан тыш, электрон образлар рәвешендә түбәндәгеләр теркәлә:

әгәр дә дәүләт теркәвенә алу өчен республика башкарма хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышмыйча чыгарыла алмаган норматив хокукый актлар составына керә торган норматив хокукый акт кертелсә, республика башкарма хакимият органы каршындагы иҗтимагый совет бәяләмәсе;

бу Кагыйдәләрнең 1.5 һәм 1.6 нчы пунктларында билгеләнгән очракларда, вәкаләтле органнар бәяләмәләре;

республика башкарма хакимият органының юридик хезмәте җитәкчесе яки аның вазыйфаларын башкаручы зат тарафыннан имзаланган, түбәндәгеләрне үз эченә алган белешмә кәгазе:

норматив хокукый актны чыгару нигезләрен;

норматив хокукый акт проектын, әгәр дә законнар нигезендә килештерү таләп ителсә, шулай ук норматив хокукый акт проектында башка республика башкарма хакимият органнарына кагылышлы нигезләмәләр булса, кызыксынучы республика башкарма хакимият органнары белән килештерү турындагы мәгълүматларны;

норматив хокукый акт проектына коррупциягә каршы экспертиза, шул исәптән коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү турындагы мәгълүматларны;

законнар белән каралган очракларда һәм тәртиптә норматив хокукый акт проектына җәмәгатьчелек фикер алышуын, иҗтимагый экспертиза үткәрү турындагы мәгълүматларны;

элемтәгә керү өчен телефон номерын һәм (яки) электрон почта адресын күрсәтеп, норматив хокукый акт проектын эшләүне гамәлгә ашырган вазыйфаи зат турындагы мәгълүматларны.

Әгәр дә норматив хокукый акт чыгарган республика башкарма хакимият органы тарафыннан аны «Республика Татарстан» һәм (яки) «Ватаным Татарстан» газеталарында бастырып чыгару турында карар кабул ителгән очракта, иярчен хатка тиешле күрсәтмә, шулай ук әлеге газеталарда дәүләт теркәвенә алынган норматив хокукый актны бастырып чыгару өчен түләү гарантиясе кертелә.

2.4. Берничә республика башкарма хакимият органнары белән бергәләп чыгарылган норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алуга тәкъдим итү норматив хокукый актны чыгарганнар арасыннан беренче булып күрсәтелгән орган тарафыннан гамәлгә ашырыла. Мондый норматив хокукый актны «Республика Татарстан» һәм (яки) «Ватаным Татарстан» газеталарында бастырып чыгару өчен түләү әлеге органнар тарафыннан үзара килешенеп гамәлгә ашырыла.

2.5. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы иярчен хатны, әлеге Кагыйдәләрнең 2.3 нче пунктында күрсәтелгән һәм теркәлгән документлар белән бергә, Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә норматив хокукый актка хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза үткәрүне гамәлгә ашыра, аның нәтиҗәләре буенча норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алу йә дәүләт теркәвенә алудан баш тарту турында карар кабул итә. Әлеге вакыт Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан озайтылырга, әмма иң күбе 30 көнгә мөмкин.

2.6. Норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алу турындагы карар Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Дәүләт теркәвенә алынган норматив хокукый акт Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары дәүләт реестрына кертелә.

2.7. Норматив хокукый акт дәүләт теркәвенә алынган көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасындагы республика башкарма хакимияте органы адресына, норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алу датасы һәм теркәү номеры күрсәтелеп, хәбәрнамә җибәрелә.

2.8. Әгәр дә хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә түбәндәгеләр ачыкланса, норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алудан баш тартыла:

законнарга туры килмәү;

коррупциоген факторлар булу;

юридик-техник характердагы җитешсезлекләр булу.

2.9. Норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алудан баш тартылган очракта, Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасындагы республика башкарма хакимияте органы адресына бу Кагыйдәләрнең 2.5 нче пунктында каралган вакыт эчендә, баш тарту нигезе күрсәтелеп, хәбәрнамә җибәрелә. Дәүләт теркәвенә алудан баш тартылган норматив хокукый акт гамәлдән чыгарылырга тиеш.

Дәүләт теркәвенә алудан баш тарту турында хәбәрнамә алынган көннән 30 көннән дә артык булмаган вакытта республика башкарма хакимият органы тиешле хокукый мөнәсәбәтләрне җайга сала торган яңа норматив хокукый акт чыгара.

2.10. Бу Кагыйдәләр белән билгеләнгән норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә бирү тәртибе үтәлмәгән очракта, бу Кагыйдәләрнең 2.5 нче пунктында каралган вакыт эчендә Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасындагы республика башкарма хакимият органы адресына, кире кайтару нигезе күрсәтелеп, хәбәрнамә җибәрелә. Норматив хокукый акт әлеге хәбәрнамә алынган көннән 10 көн эчендә дәүләт теркәвенә яңадан бирелергә тиеш.

2.11. Республика башкарма хакимият органы тәкъдим ителгән норматив хокукый актны, аны дәүләт теркәвенә алганга кадәр, кире соратып алырга хокуклы.

## III. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару

3.1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынган норматив хокукый актлар (дәүләт серен яки конфиденциаль характердагы мәгълүматларны үз эченә алган актлардан һәм аларның аерым нигезләмәләреннән башка) аларны дәүләт теркәвенә алган көннән соң 10 көн эчендә рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

3.2. Норматив хокукый актларны рәсми бастырып чыгару булып аларның тулы текстларын «Республика Татарстан», «Ватаным Татарстан», «Татарстан Республикасы законнары җыелмасы» газеталарында беренче тапкыр бастыру яки Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) беренче тапкыр урнаштыру (бастырып чыгару) санала. Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау мәсьәләләре буенча норматив хокукый

актларны рәсми бастырып чыгару булып шулай ук аларның тулы текстларын Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталында (pravo.gov.ru) беренче тапкыр урнаштыру (бастырып чыгару) санала.

3.3. Дәүләт теркәвенә алу турында хәбәрнамә алган республика башкарма хакимият органы, бу Кагыйдәләрнең 3.1 нче пункты белән билгеләнгән вакыт чыкканга кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, норматив хокукый акт текстын рус һәм татар телләрендә pdf һәм doc яки docx форматларындагы электрон рәвештә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына кертә.

Норматив хокукый акт текстларының рус һәм татар телләрендә тәңгәллеге, шулай ук норматив хокукый актның электрон образы эчтәлегенең кәгазьдәге текстына тәңгәллеге өчен норматив хокукый актны чыгарган республика башкарма хакимият органы җавап бирә.

3.4. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы норматив хокукый актның рус һәм татар телләрендәге текстларын алганнан соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча:

норматив хокукый актны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыра;

норматив хокукый актны Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша «Татарстан Республикасы законнары җыелмасы» журналы редакциясенә, шулай ук бу Кагыйдәләрнең 2.3 нче пунктындагы унынчы абзацы белән каралган очракта «Республика Татарстан» һәм (яки) «Ватаным Татарстан» газеталары редакциясенә җибәрә;

кеше һәм граждан хокукларын һәм иреккләрен яклау мәсьәләләре буенча норматив хокукый актны Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталында (pravo.gov.ru) урнаштыруны тәэмин итә.

3.5. Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары аларны рәсми бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

Кеше һәм граждан хокукларына кагылышлы норматив хокукый актлар аларны рәсми бастырып чыгарган көннән соң 10 көннән дә иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Норматив хокукый актлар белән аларның үз көченә керүенең башка вакыты билгеләнергә мөмкин.

3.6. Норматив хокукый актны бастырып чыгарганда һәм таратканда аның дәүләт теркәвенә алу датасын һәм Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары дәүләт реестрындагы номерын күрсәтү мәҗбүри булып тора.

3.7. Дәүләт теркәвенә алынмаган һәм бу Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә басылып чыкмаган норматив хокукый актлар кулланылмаска тиеш.

---